ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.11.2023 п.г.т.Алексеевское № 468

**Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының «Алексеевск муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затларның исемлеген билгеләү турында» 2020 елның 07 августындагы 311 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 21 июлендәге 67-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән

**карар бирәм**:

1. Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Алексеевск муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» 07.08.2020 № 311 карарының 1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. Үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләргә, административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының (Кушымта)2.1, 2.4 – 2.7, 2.12 – 2.13, 2.17, 2.19, 2.20, 2.21, 3.2 – 3.6, 3.8, 3.10, 3.11, 3.14 – 3.17, 4.4, 5.1, 5.2, 5.6 статьяларында күздә тотылганча(Кушымта)».

2. «Алексеевск муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 07.08.2020 ел, № 311 карарына кушымтаны сүзләр белән тулыландырырга:

| | | |
|---|---|---|
| | **ТР АХБ Кодексының 2.21 Статьясы**<br>Татарстан Республикасы территориясендә билгеләнгән режим | - «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |

| | | |
|---|---|---|
| | (база әзерлеге дәрәҗәсе) кысаларында чараларны гамәлгә ашыруны күздә тотучы Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү, әгәр бу хокук бозуларга җинаять җәзасы каралмаган яки административ җаваплылыкка тартылуны административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексы нигезендә күздә тотмыйлар икән | |

3. Кадрлар буенча эш алып бару өчен җаваплы кешегә (Демидова А.Д.) административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле затларның вазифа инструкцияләренә үзгәрешләр кертергә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматларының рәсми порталында, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е. А. Хәмзинага йөкләргә

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **М.Р. Гайсин**